БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 28 » апрель 2018 ел № 127

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында**

Хезмәт өчен түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, социаль гарантияләрне тәэмин итү, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри эшчәнлекләрен стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 мартындагы 197 номерлы, «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы

вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата бүләкләүләрне 1-3 нче кушымталар нигезендә.

2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган, муниципаль хезмәтнең биләгән вазыйфасына карап, 11163 сум күләмендә булган муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладларына тигез булган коэффициентларны 4-6 нчы кушымталар нигезендә.

3) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 7 нче кушымта нигезендә.

4) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 8 нче кушымта нигезендә.

5) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә класслы чины өчен айлык өстәмә түләү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 9 нчы кушымта нигезендә.

6) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык акчалата бүләкләү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 10 нчы кушымта нигезендә.

7) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә ел саен түләнә торган отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 11 нче кушымта нигезендә.

8) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре күләмен һәм аны билгеләү һәм исәпләү тәртибен 12 нче кушымта нигезендә.

9) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә аеруча мөһим һәм катлаулы йөкләмәләр башкарган өчен премия түләүләре күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 13 нче кушымта нигезендә.

10) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә матди ярдәм күрсәтү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 14 нче кушымта нигезендә.

11) Төп хезмәт вазыйфаларына хокукый актларга һәм хокукый актлар проектларына хокукый экспертиза үткәрү, хокукый актлар проектларын әзерләү һәм редакцияләү, югары юридик белемгә ия булган юрист яки башкаручы сыйфатында визалау кергән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә айлык түләү (юридик эш өчен өстәмәләр) күләмен һәм аны гамәлгә ашыру тәртибен 15 нче кушымта нигезендә.

12) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә профильле фәннәр кандидаты, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү күләмен һәм аны билгеләү тәртибен 16 нчы кушымта нигезендә.

13) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладына Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, күләмнәрдә һәм тәртиптә эшләгән өчен айлык өстәмә түләү күләмен һәм аны гамәлгә ашыру

тәртибен 17 нче кушымта нигезендә.

2. Расларга:

1) Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органының сайланулы вазыйфаи затына һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенә пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында нигезләмәне 18 нче кушымта нигезендә.

2) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләве тәртибе турында нигезләмәне 19 нчы кушымта нигезендә.

3) Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисенең һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру тәртибен 20 нче кушымта нигезендә.

3. Үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2010 елның 19 февралендәге 169 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында нигезләмә.

2) «Даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү түләвен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2012 елның 29 августындагы 124 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район Советы карары.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарына норматив-хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәм pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин